СИШӘМБЕ
2 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 76 (5876)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—23, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Уникенче Союзный Социалистик Республика

Кичә СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турындагы законны бер тавыштан кабул итте. Совет Социалистик Республикалар Союзында берләшкән ирекле халыкларның бөек семьясендә хәзер инде унбер түгел, ә унике тигез хокуклы ил бар. Бу—зур тарихи вакыйга, бу—Ленин—Сталин милли политикасының яңа җиңүе.

Яңа, уникенче Союзный республика төзелү—фин ак гвардеецларына каршы көрәштә Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе ирешкән гүзәл җиңүнең турыдан-туры нәтиҗәсе. Социализм иленең кораллы көчләре Ленинградка, дөньяның зур пролетар үзәгенә һөҗүм итү өчен хәзерләнгән плацдармны җимерделәр, СССР ның төньяк-көнбатыш чикләре өстендә куерган империалистик һөҗүм куркынычын бетерделәр. Советлар иленә һөҗүм итү өчен төрле дәүләт империалистларының берләштерелгән көчләре тарафыннан куәтле плацдарм итеп төзелгән территорияләр бүгеннән башлап Советлар Союзы территориясе булып әверелделәр. 1940 нчы елның 12 нче мартында СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры буенча шул җирләр Советлар Союзына күчтеләр. Алар сугыш учагыннан тынычлык терәге булып һәм безнең төньяк-көнбатыш чикләребезнең куркынычсызлык терәге булып әверелделәр, алар мәңгегә куәтле социалистик державаның аерылгысыз өлеше булып әверелделәр.

Билгеле, Финляндия территориясенең бер өлеше СССР га күчкәннән соң яңа җирләрнең дәүләт төзелешенең нинди булырга тиешлеге турындагы мәсьәлә килеп басты. Карелия Республикасының хезмәт ияләре бу территорияләрнең Карелия составына керүенә теләкләрен белдерделәр. Союз хөкүмәте бу законлы һәм гадел теләкләргә каршы килмәде. Ул монда күп милләтле социалистик дәүләтнең дәүләт төзелеше нигезенә салынган төп принциптан,— Ватаныбызда яшәүче барлык милләтләрнең ирекле үсүләре принципыннан—Ленинчел — Сталинчыл принциптан чыгып эш итте. Союз хөкүмәте тарафыннан СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе карамагына кертелгән һәм кичә Совет властеның югары органы тарафыннан бер тавыштан расланган законда болай дип язылган: Финляндиядән СССР га күчкән территория, турыдан-туры Ленинградка караган кечрәк полосадан башкасы, Карелия АССР составына тапшырыла, шул исәптән Выборг, Антреа, Кексгольм, Сортавала, Суоярви, Куолаярви шәһәрләре тапшырыла.

Бары тик ирекле социалистик илдә генә һәрбер халыкның интересларына тулысынча туры китереп милли мәсьәлә шулай тиз һәм җиңел хәл ителә. Безнең күп милләтле дәүләтебезнең көче һәм куәте, җиңелмәслеге һәм ныклыгы шунда ки, ул Карпаттан алып Тын океанга кадәр СССР да яшәүче барлык зур һәм кечкенә халыкларга ирекле рәвештә иҗади дәүләт үсешен тәэмин итә.

„Империалистик сугыш уңае белән чиктән тыш кискенләшкән империалистик коллык, милли һәм колониаль изү эпохасында, кечкенә дәүләтләрнең хокуклары һәм интереслары империалистлар кулында уенчык кына булган чорда яңа союзный республика төзелү азчылык халыкларга ирекле төстә милли үсеш өчен тулы мөмкинлек тәэмин итә торган совет строеның төп өстенлекләрен аеруча көч белән күрсәтә“ (Жданов).

Һич шиксез, яңа оештырылган, уникенче Союзный Республиканың хезмәт ияләре—Карел-Фин ССР эшчеләре, колхозчылары, интеллигенциясе, республиканың дәүләт, экономика, культура үсеше өчен тагын да зуррак перспективалар һәм мөмкинлекләр ачучы тарихи законны зур шатлык белән каршы алырлар.

Кыргый край, артта калган патша колониясе булган Карелия Совет власте елларында үзенең хуҗалыгын, үзенең культурасын өзлексез үстерүче чәчәк атучы ил булып әверелде. Карелия—гаять күп табигый байлыклар иле. Аның гаять зур урманнарында миллиард кубометрдан артык агач бар. Урман—республикада халык хуҗалыгының төп тармагы. Гаять күп җир асты байлыклары—диабаз, шпат, кварц, гранит, мрамор, слюда запаслары бар. Слюда чыгару буенча Карелия Советлар Союзында беренче урыннардан берсен алып тора. Карелия җирләрендә бик күп төрле рудалар—цинк, аккургашын, бакыр, көмеш, молибден, каракургашын, барит һ. б. бар.

Карелиянең җир астында, күлләрендә, елгаларында, урманнарында булган табигый байлыкларны кыскача исемлектә генә күрсәтеп бетерү мөмкин түгел. Бу байлыкларга йөз еллар һәм мең еллар буена кул тиелмәгән. Тик Бөек Октябрь Социалистик революциясе җиңгәннән соң гына алардан тулы һәм рациональ файдалану өчен шартлар тудырылды. Монда заводлар, фабрикалар, электр станцияләре төзелә башлады. Сталинчыл бишьеллыклар елларында Карелиядә 20 дән артык промышленность предприятиеләре төзелде. 1938 нче елны Кондопогада пегматит заводы—пегматит эшләү буенча Советлар Союзында бердән-бер предприятие эксплоатациягә бирелде. 1939 нчы елның 1 нче кварталында Сегежа кәгаз-целлюлоза комбинаты (беренче өлеше) стройга керде. Комбинат иң яңа техника белән җиһазландырылган һәм һәр елны ун меңнәрчә тонна товарлыклы целлюлоза, кәгаз һәм башка продукция эшләп чыгарачак. Комбинат янында дүрт рамлы такта яру заводы корыла. Ак диңгез—Балтык каналының Карелиянең хуҗалык үсешендә гаять зур әһәмияте булды.

Революциягә кадәр Олонец губернасында (хәзерге Карелиядә) авыл хуҗалыгы чиктән тыш артта калган иде, гади һәм аз җитештерүчән иде. Крестьяннарнең зур күпчелеге ярым ач яшәүгә дучар ителгән иде. Ләкин бу лагнәт тормыш мәңгегә югалды. Ваклаган крестьян хуҗалыклары урнына хәзер эре социалистик авыл хуҗалыгы төзелде.

Царизм карел халкын караңгылыкта тотты һәм аның культура үсешенә барлык чаралар белән комачаулады. 1913 нче елны Олонец губернасында халыкның 44 проценты укый-яза белә иде, ә авыл халкы арасында ул бары 23 процент иде. Олонец губернасындагы кареллар арасында укый-яза белүчеләр бары 13 процент иде.

Социалистик төзелешнең уңышлары Карелиянең культура үсешен тәэмин итте. Карелия халкы арасында укый-яза белүчеләр хәзер 95 процентка җитә. Карелларның әдәби телен булдыру зур казаныш булды, карел балалары хәзер шушы телдә укытылалар. Карелиядә 3 югары уку йорты һәм 12 техникум ачылды, 28 басма газета һәм 2 журнал чыгарыла. Республиканың һәрбер районының үз газетасы бар.

Карелия АССР ны Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү, Финляндиядән күчкән территориядәге промышленностьны, (Гомуми Союз күләмендә әһәмияте булган аз сандагы предприятиеләрдән тыш) яңа союзный республикага бирү белән республиканың экономикасын, культурасын һәм хезмәт ияләренең көнкүрешен тагын да тизрәк үстерү өчен мөмкинлекләр туа. СССР Верховный Советы депутатлары, Карелия халкының вәкилләре Соляков һәм Горбачев иптәшләр, Верховный Советның VI нчы Сессиясенең биек трибунасыннан, яңа союзный республика алдынгылар сафына чыгу өчен үзенең бөтен көчен куяр дип бөтен илне, хөкүмәтне, партияне, иптәш Сталинны ышандырдылар. Алар Карелиянең барлык хезмәт ияләренең омтылышын һәм хисен чагылдырдылар. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә яңа союзный республика—Карел-Фин ССР илебездәге барлык республикалар белән берлектә коммунизмның яңа җиңүләренә барыр.

(*„Правда“ 1 апрель*).

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

КАРЕЛИЯ АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫН СОЮЗНЫЙ КАРЕЛ-ФИН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ИТЕП ТӨЗҮ ТУРЫНДА

Депутат А. А. ЖДАНОВ доклады

Иптәшләр, Верховный Совет депутатлары!

СССР белән Финляндия республикасы арасында төзелгән солых договоры буенча Финляндиядән Совет Социалистик Республикалар Союзына яңа территорияләр һәм шул исәптән Выборг (Выпури) шәһәре һәм Выборг заливы һәм андагы атаулар белән берлектә бөтен Карелия бугазы, Кексгольм, Сортавала, Суоярви шәһәрләре белән берлектә Ладога күленең көнбатыш һәм төньяк яр буе, Куолаярви шәһәре белән берлектә Меркярвидән көнчыгыштарак булган территория кушылды. Мәгълүм ки, бу территорияләр һәм бигрәк тә Карелия бугазы, әле күптән түгел генә Совет Социалистик Республикалар Союзына һәм беренче чиратта Ленинградка сугыш һөҗүмнәре ясау өчен сугыш техникасының иң соңгы яңалыклары нигезендә җиһазландырылган плацдармнан гыйбарәт иде. Хәзер, Финляндиягә каршы сугышта фин армиясен һәм аның белән берлектә Советлар Союзына аеруча дошман булган күп кенә империалистик илләрнең берләшкән көчләрен тар-мар итеп, безнең төньяк-көнбатыш чикләребездә иң куркынычлы сугыш учагын бетергән Кызыл Армиябезнең героик җиңүләре нәтиҗәсендә бу территорияләр үзләре әлегә кадәр булганга караганда бөтенләй башкача әһәмият алалар. Алар сугыш учагыннан хәзер тынычлык һәм куркынычсызлык терәге булып, барыннан да элек Ленинградка, шулай ук Мурманскига һәм Мурманск тимер юлына куркынычсызлык терәге булып әверелделәр.

Совет Социалистик Республикалар Союзына яңа территорияләрнең кушылуы, табигый рәвештә, аларның иң уңайлы дәүләт төзелеше турындагы һәм аларның хуҗалык һәм культура үсеше юллары турындагы мәсьәләне куя.

Бик азларын гына исәпкә алмаганда, бу территорияләр Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасына якын торалар һәм табигый, тарихи шартларының характеры буенча да, шулай ук үзләренең халык хуҗалыгы эшләренең юнәлеше буенча да аңа карыйлар.

Шуңа күрә дә Финляндиядән СССР га күчкән яңа территорияләрнең дәүләт төзелеше турындагы мәсьәләне тикшергәндә Халык Комиссарлары Советы, турыдан-туры Ленинградка карый торган аз гына полосадан кала, Финляндиядән Совет Социалистик Республикалар Союзына күчкән территорияләрне Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы составына бирү, шул исәптән Выборг, Антреа, Кексгольм, Сортавала, Суоярви, Куолаярви шәһәрләрен дә бирү турында Карелия республикасы хезмәт ияләренең законлы һәм урынлы теләкләрен тулысынча искә алды. ССР Союзы Совнаркомы тиешле тәкъдимне Верховный Совет карамагына кертә. Әгәр дә Верховный Совет бу тәкъдимне кабул итсә, анардан шулай ук Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы хезмәт ияләренең теләкләренә нигезләнгән икенче бер тәкъдим—Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турындагы тәкъдим дә килеп чыга (**кул чабулар**).

Депутат иптәшләр! Карелия Автономияле Совет Социа-

листик Республикасы яши башлавының 20 нче елына керде. 1920 нче елны карел халкы үзенең милли автономиясенә нигез салды. 1921 һәм 1922 нче елларда ак финнәргә каршы көрәшләрдә карел халкы, рус халкының ярдәме белән, Совет власте байрагы астында үзенең мөстәкыйл дәүләт булып үсү хокукын саклап калды.

Карелия АССР үзенең яшәве елларында чәчәк атучы Совет иле булып әверелде. Ленин—Сталин милли политикасын тайпылышсыз үткәрү нигезендә, большевиклар партиясе һәм бөтен дөнья халыкларының һәм хезмәт ияләренең юлбашчысы иптәш Сталин җитәкчелегендә, Карелия халкы рус халкының туганлык ярдәме белән, социалистик төзелешнең һәм үзенең милли культурасын төзүнең барлык өлкәләрендә зур уңышларга ирешә (**кул чабулар**). Элекке патша Россиясенең кайчандыр артта калган окраинасы, патша империализмының колониясе булган Карелия тизлек белән үсүче промышленносте һәм авыл хуҗалыгы булган ил булып әверелде, авыл хуҗалыгын үстерүдә, культураны үстерүдә һәм халыклар массасының тормыш дәрәҗәсен күтәрүдә бик нык алга атлады.

Совет автономиясе, иптәш Сталин билгеләвенчә, мәңгелеккә бирелгән һәм катып калган нәрсә түгел, ул үзенең үсешендә бик күп төрле формаларны һәм баскычларны үтә ала.

Карелия составына яңа территорияләр кушылу аның тоткан урнын һәм әһәмиятен яңа баскычка күтәрә һәм аның милли халык хуҗалыгы һәм культура үсеше эшендә Карелия алдына яңа зур бурычлар куя. Карелия хезмәт ияләре кебек үк, ССР Союзы Совнаркомы да бу яңа бурычлар Карелиянең милли дәүләт булып яшәвенең яңа формаларында — Союзный Карел-Фин Республикасында уңышлы рәвештә хәл ителәчәкләр дип саный.

Совет власте СССР га күчкән районнарны Карелиянең төп районнары белән бергә бәйләү өчен чаралар күрде инде. Хәзер Петрозаводск — Суоярви тимер юлы үткәрелде, бу юл Карелиянең башкаласы Петрозаводск шәһәрен һәм Мурманск тимер юлын Сортавала—Выборг тимер юлы магистрале белән тоташтыра. Аннары Кандалакшадан Куолаярвига кадәр тимер юл үткәрелә һәм тиздән бу эш тәмам булачак, бу юл төп Карелияне Куолаярви районында СССР га күчкән территория белән тоташтырачак.

Карелия составына кертелә торган территориядә урнашкан промышленность предприятиеләре, бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган аз гына сандагы предприятиеләрдән башкалары, Карел-Фин ССР карамагына биреләчәкләр.

Карелия республикасын Союзный республика итеп төзү уңае белән аның исмен үзгәртергә кирәклек турында берничә сүз. Карелиягә бирелә торган районнар карел районнары гына түгел, бәлки бер кадәр саф фин районнары да. Фин һәм карел халыклары раса-милләт ягыннан үзара бәйләнгәннәр. Карелия Автономияле Республикасын Союзный Карел-Фин республикасы итеп төзү бу ике кардәш халыкның хуҗалык һәм культура ягыннан тагын да үсүләренә һәм аларның туганнарча дуслыклары ныгуга ярдәм итәчәк. Ул фин һәм карел халыкларының дошманнары тарафыннан күп еллар буена бу ике халык арасында җәелдереләп килгән дошманлыкка һәм талашларга чик куячак.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Халык Комиссарлары Советы миңа Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турында түбәндәге закон проектын Верховный Совет карамагына кертүне тапшырды.

Закон проектын игълан итәм:

„Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турында“.

Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы хезмәт ияләренең теләгән үтәү йөзеннән һәм милләтләрнең ирекле үсеше принципын кулланып, Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы карар бирә:

1. 1940 нчы елның 12 нче мартында СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры нигезендә Финляндиядән СССР га күчә торган территорияне, турыдан-туры Ленинградка караган кечрәк полосадан башкасын, Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы составына тапшырырга, шул исәптән Выборг, Антреа, Кексгольм, Сортавала, Суоярви, Куолаярви шәһәрләрен тапшырырга.

2. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзергә.

3. Шушы законның беренче пункты буенча Карелия составына кушыла торган территориядә урнашкан промышленность предприятиеләрен, бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган аз гына сандагы предприятиеләрдән башкаларын, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы карамагына тапшырырга.

4. Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советыннан һәм Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы Верховный Советыннан РСФСР белән Карел-Фин ССР арасында төгәл чикне билгеләү проектын СССР Верховный Советы карамагына кертүләрен сорарга.

5. СССР Конституциясенең (Төп Законының) 34 һәм 35 нче статьяләренә туры китереп Карел-Фин Совет Социалистик Республикасыннан СССР Верховный Советына депутатлар сайлау үткәрергә.

6. СССР Верховный Советы Президиумына бу сайлауларның көнен билгеләүне тапшырырга.

7. Шушы законга туры китереп, СССР Конституциясенең (Төп Законының) 13 нче статьясенә өстәмә кертеп, аны түбәндәгечә язарга:

„**13 статья.** Совет Социалистик Республикалар Союзы тигез хокуклы Совет Социалистик Республикаларның:

Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының,

Украина Совет Социалистик Республикасының,

Белоруссия Совет Социалистик Республикасының,

Азербайҗан Совет Социалистик Республикасының,

Грузия Совет Социалистик Республикасының,

Әрмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Төрекмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасының,

Таҗикстан Совет Социалистик Республикасының,

Казагстан Совет Социалистик Республикасының,

Кыргызстан Совет Социалистик Республикасының,

Карел-Фин Совет Социалистик Республикасының ихтиярлы берләшүләре нигезендә төзелгән союз дәүләте“.

Депутат иптәшләр! Халык Комиссарлары Советы бу законның һәр ике палата тарафыннан бердәмлек белән яхшы дип табылачагына ышана (**озакка сузылган кул чабулар**).

Депутат иптәшләр! Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Совет Социалистик Республикасы итеп төзү милләтләрнең тигезлеген, барлык халыкларның бергәләп тыныч яшәүләрен һәм туганнарча дуслыгын тәэмин итә торган Ленин—Сталин милли политикасының яңа зур җиңүе дигән сүз. Үзенең милли дәүләт булып яшәвенең яңа формаларында карел-фин халкы үзендә булган иҗад сәләтләренең бөтен байлыгын тагын да җәелдерер, Сталин Конституциясе байрагы астында тагын да тизрәк, тагын да зуррак уңышлар белән алга барыр (**кул чабулар**).

Кардәш Союзный Республикалар семьясендә яңа союзный республика килеп чыга. Бу, безнең күп милләтле Совет дәүләтен ныгыту эшендә яңа адым дигән сүз.

Империалистик сугыш уңае белән чиктән тыш кискенләшкән империалистик коллык, милли һәм колониаль изү эпохасында, кечкенә дәүләтләрнең хокуклары һәм интереслары империалистлар кулында уенчык кына булган чорда яңа союзный республика төзелү азчылык халыкларга ирекле төстә милли үсеш өчен тулы мөмкинлек тәэмин итә торган совет строеның төп өстенлекләрен аеруча көч белән күрсәтә.

Карел-Фин Союзный Республикасы тынычлыкның һәм төньяк-көнбатыш чикләрдә Совет Социалистик Республикалар союзына куркынычсызлыкның ныклы терәге генә түгел, бәлки алдынгы союзный республикаларның берсе булыр дип ышаныч белдерергә рөхсәт итегез (**озакка сузылган кул чабулар**).

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

1940 НЧЫ ЕЛ НАВИГАЦИЯСЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК ТУРЫНДА

1940 нчы ел навигациясенә хәзерлек мәсьәләсе 1939 нчы елның декабрендә ВКП(б) Өлкә Комитетында махсус рәвештә тикшерелде. Судноларны ремонтлау заводлары директорлары, партбюро секретарьлары һәм ВКП(б) райкомнары вәкилләре катнашы белән үткәрелгән бу киңәшмәдә ремонт эшләрен ничек итеп тиз һәм югары сыйфат белән үткәрү буенча конкрет чаралар билгеләнгән иде.

Шушы чараларның үтәлешен тикшерү йөзеннән чыгып, 31 нче мартта ВКП(б) Өлкә Комитетында затон директорлары һәм партбюро секретарьларының киңәшмәсе булды. ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Абдельманов җитәкчелегендә үткәрелгән бу киңәшмә Куйбышев һәм Аракчино затоннары директорларының, шулай ук Казан һәм Кама Тамагы пристаньнәре начальникларының докладларын тыңлады, республикабызда навигациягә хәзерлекнең торышын тикшерде.

Киңәшмә, судноларга һәм пристаньнәргә, шулай ук склад хуҗалыкларына ремонт эшләренең барышын, гомумән навигациягә хәзерлекнең торышын канәгатьләнерлек түгел дип тапты. Бу эш Чистай, Куйбышев һәм Аракчино затоннарында бигрәк тә йомшак оештырылган. Монда әле дистәләрчә суднолар яртылаш та ремонтланмаганнар.

Киңәшмә, затон һәм пристаньнәрнең хуҗалык һәм партия оешмалары җитәкчеләрен судноларга ремонт эшен 10 нчы апрельгә, ә пристаньнәрне һәм склад хуҗалыкларын ремонтлауны 15 нче апрельгә төгәлләргә, навигациягә тулы хәзерлекне тәэмин итү өчен барлык чараларны күрергә, навигациягә хәзерлекнең йомгакларын партиянең ачык җыелышларында тикшерергә, алда торган җаваплы бурычларны уңышлы башкаруга масса активлыгын тупларга, партия-масса эшен киң рәвештә җәелдерергә мәҗбүр итте. ВКП(б) ның Юдино, Куйбышев, Чистай, Югары Ослан, Чаллы һәм Акташ райкомнарына навигациягә хәзерлекнең йомгакларын бюро утырышларында тикшерергә, су юлы транспорты работникларына практик ярдәмне кискен рәвештә яхшыртырга кирәклеге әйтелде.

ССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

1940 нчы елга СССР ның дәүләт бюджеты турында һәм ССР Союзының 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турында

СССР Финанс Халык Комиссары иптәш А. Г. Зверевның 1940 нчы елның 31 нче мартында ССР Союзы Верховный Советы утырышында ясаган доклады

Депутат иптәшләр! ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Совет Социалистик Республикалар Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын сезнең раславыгызга кертә. Шул ук вакытта сезнең раславыгызга ССР Союзының 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы отчет кертелә.

ССР Союзының дәүләт бюджеты 1940 нчы елгы халык хуҗалыгы планына туры китереп төзелгән. Дәүләт бюджеты билгеләнгән доходлар һәм расходлар үсеше илебезнең социалистик хуҗалыкларга гаять зур казанышларга нигезләнгән һәм Сталинчы өченче бишьеллыкның өченче елында халык хуҗалыгы, культура һәм оборона төзелеше өлкәсендә хәл итәргә кирәк булачак бурычлар белән билгеләнгән.

Үткән 1939 нчы ел совет халкына зур уңышлар китерде. Ватаныбызның куәте тагын да үсте, Советлар Союзының халыкара авторитеты тагын да нығыды. Советлар Союзы халыкларының тату семьясе 13 миллион кешегә артты: аңа безнең кардәш туганнарыбыз, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыклары—поляк алпавытларының һәм капиталистларының изүеннән героик Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән халыклар керделәр.

1939 нчы елның декабрендә безнең илебездә хезмәт ияләре депутатларының жирле Советларына сайлаулар булды. Алар совет халкының җимерелмәслек морально-политик бердәмлеген бөтен доньяга тагын һәм тагын бер кат күрсәттеләр. Бу сайлаулар большевиклар партиясенең һәм халыклар юлбашчысына, безнең барлык җиңүләребезне рухландыручы һәм оештыручы бөек Сталинга карата бөтен халык мәхәббәтенең онытылмаслык зур демонстрациясе булдылар. (Көчле кул чабулар).

1940 нчы елны Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләреннән СССР Верховный Советына, УССР һәм БССР Верховный Советларына сайлаулар да шулай ук бөек Ленин—Сталин эшенең тантанасы булды. Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләре коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчы блогы кандидатларына бердәмлек белән тавыш биреп, үзләренең социалистик Ватанга булган мәхәббәтләрен, бөтен совет халкы белән берлекте, Сталин Конституциясе байрагы астында коммунизм төзүгә булган ныклы омтылышларын күрсәттеләр.

1939 нчы елгы иң әһәмиятле хуҗалык йомгаклары промышленность производствосының бик нык үсүеннән гыйбарәт. 1939 нчы елны промышленность продукциясе 14,7 процентка артты, ә 1938 нче елны 11,8 процентка арткан иде. Промышленность производствосының бу үсеше ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан илебез алдына куелган тарихи бурычларның уңышлы үтәлүен күрсәтә.

Промышленность продукциясенең үсүе стахановчылык хәрәкәтенең тагын да җәелүенә аерылгысыз рәвештә бәйләнгән. 1939 нчы елны социалистик ярышның яңа формалары—күп станокчылар хәрәкәте һәм берьюлы берничә профессиягә эшләү туды һәм киң күләмдә җәелде. Үткән елны промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеге 16,7 процентка артты.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә уңышлар аз булмады. Бөртекле ашлыклар уңышы 1938 нче елга чагыштырганда артыграк булды. Колхозларда мөгезле терлекләр саны шактый артты.

Илебезнең политик һәм хуҗалык тормышының барлык өлкәләрендә 1939 нчы елны ирешелгән уңышлар Советлар Союзының финанс хуҗалыгында да чагылыш таптылар.

1938 нче елгы дәүләт бюджеты доходлар буенча 127,5 миллиард сумлык итеп, ә расходлар буенча 124 миллиард сумлык итеп үтәлде. Доходлар расходларга караганда 3,5 миллиард сум артык булды.

Халык хуҗалыгының 1939 нчы елны тагын да алга китүе безнең финансларыбызның да үсүе өчен уңайлы шартлар тудырды. ССР Союзының 1939 нчы елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы башлангыч саннар бюджет доходларының 1938 нче елга чагыштырганда 1939 нчы елны 22,3 процентка артканлыгын күрсәтәләр. Бюджетка барлыгы 155,9 миллиард сум керде (планның 99,9 проценты), ә 153,1 миллиард сум тотылды (планның 98,5 проценты). 1939 нчы елны доходлар расходлардан 2,8 миллиард сумга артык булдылар.

СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты сезнең раславыгызга доходлар буенча 182,6 миллиард сумлык һәм расходлар буенча 179,7 миллиард сумлык күләмендә, ә Союз бюджетының ел ахрына Госбанктагы хисапларда план буенча кала торган сумаларын кертеп исәпләгәндә 181,2 миллиард сумлык күләмендә кертелә. Доходлар расходларга караганда 1,4 миллиард сум артык булачак.

1939 нчы елга чагыштырганда ССР Союзының дәүләт бюджеты 1940 нчы елны доходлар буенча 26,7 миллиард сумга, яки 17,1 процентка арта.

Союз бюджеты буенча доходларның гомуми күләме 140 миллиард сумлык, ә расходлар 138,6 миллиард сумлык итеп билгеләнде. Союзный республикалар, Автономияле республикалар һәм җирле Советлар бюджетларының күләме 42,6 миллиард сумлык итеп билгеләнде.

СССР ның—Союзный, республика һәм җирле дәүләт бюджетының доход өлеше 1940 нчы елга түбәндәге төп керемнәрдән төзелә (миллион сумнар белән):

Доход чыганаклары	Сумасы
Барлык доходлар	182.585,9
Шул исәптән:	
Оборот налогы	108.349,0
Табышлардан чигерүләр	22.367,9
Дәүләт социаль страхованиесе средстволары	9.136,0
Машина - трактор станцияләре доходлары	2.623,4
Дәүләт заемнары	11.171,0
Халыктан налоглар һәм җыемнар	9.703,8

1940 нчы елга оборот налогы 108,3 миллиард сумлык итеп билгеләнә: үткән елга караганда үсеш 11,5 миллиард сум, яки 11,9 процент. Оборот налогы керемнәре товарлыклы продукция чыгаруга караганда бер кадәр акрынрак үсәчәкләр, бу соңгысы 1940 нчы елны 1939 нчы елга чагыштырганда 13,6 процентка артырга тиеш. Бу, халык хуҗалыгының кайбер тармаклары буенча табышларны арттыру теләге белән налог ставкаларын киметергә билгеләү белән аңлатыла.

1939 нчы елны хөкүмәт дәүләт доходлары буенча эшне яхшырту чараларын күрде. Икмәк продуктлары, ит продуктлары, консервлар, кондитер әйберләре һәм күп кенә башка товарлар буенча оборот налогы ставкалары яңадан каралды. Планлаштыру да шактый тәртипкә салынды. Оборот налогы салу тәртибе турындагы инструкция яңадан каралды. Бюджетка түләүләрнең керүенә финанс органнарының контроле шактый көчәйтелде. Болар барсы да бюджетның доход өлешенең үтәлүенә яхшы йогынты ясадылар. 1939 нчы елны бюджетка планнан тыш 4.085 миллион сум оборот налогы керде.

Ләкин дәүләт доходларын арттыру өчен бөтен мөмкинлекләр файдаланылдымы соң? Юк, бөтенесе дә түгел. Җирле хуҗалыкны гына булса да алып карыйк. Ул бюджет доходларын өстәмә рәвештә үстерү өчен җидди чыганак була ала һәм булырга тиеш. Җирле Советлар һәм финанс органнары җирле хуҗалык белән тиешенчә шөгыльләнделәр дип, анда эчке резервларны эзләделәр дип әйтеп булмый. Шул ук вакытта финанс аппаратындагы алдынгы кешеләрнең тәҗрибәсе, әгәр дә финанс органнары җирле предприятиеләрнең эшенә тирәнтен игтибар бирсәләр һәм җирле рессурслар исәбенә промышленность һәм азык товарлары җитештерүне киңәйтү турында партия һәм хөкүмәт директиваларын ныклык белән тормышка ашырсалар, аларның бу юнәлештә күп нәрсәләр эшли алачакларын күрсәтә.

1940 нчы елның товар обороты 15,7 процентка арта. Димәк, оборот налогы кереме буенча билгеләнгән программаның ныклы экономик базасы бар. Товарларны кулланучыга җиткерүгә контроль кую, товар рессурсларын иң күп күләмдә арттыру өчен көрәш хуҗалык һәм финанс органнары җитәкчеләренең игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Беренче алынган саннарга караганда 1939 нчы елны табышлардан чигерүләр бюджет буенча билгеләнгән 17,7 миллиард сумлык урнына 15,4 миллиард сумлык булган (хуҗалык органнарының үзләренең оборот сумаларының артык өлешен алуны кертеп исәпләгәндә). Чигерүләрнең җыелып бетмәве халык хуҗалыгының кайбер тармакларының продукция чыгару буенча үзләре өчен расланган планнарны, үзенә төшү бәясен киметү заданиеләрен үтәмәүләреннән һәм шулай итеп сума туплау планнарының үтәлеп җитмәвеннән килеп чыккан.

1940 нчы елга халык хуҗалыгының барлык табышлары 33,3 миллиард сум күләмендә билгеләнде. Бюджетка табышлардан чигерүләр 22,4 миллиард сумлык итеп билгеләнде, бу, 1939 нчы елга чагыштырганда 45 процентка артык дигән сүз.

Табышларны проектта күрсәтелгәнчә арттыру барыннан да элек промышленностьта эшчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеген 1940 нчы елга 11 процентка арттыруны билгеләүгә, шулай ук продукциянең үзенә төшү бәясен 1939 нчы елга чагыштырганда 2,8 процентка киметүгә (җибәрү бәяләренең үзгәрүен исәпкә алмыйча) нигезләнгән, бу соңгысы 4,7 миллиард сум өстәмә сума бирәчәк.

Үзенә төшү бәясен киметү буенча 1940 нчы елга билгеләнгән задание—минималь задание. Ул үтәлеп кенә калмый, бәлки арттырып үтәлә ала. Моның өчен производствода югалтуларны бетерергә, хуҗалыкта булган гаять зур резервларны хәрәкәткә китерергә кирәк.

Аннары докладчы машина төзелеше заводларында, промышленностьның башка тармакларында, аерым алганда төсле металлургия предприятиеләрендә бракта зур югалтулар булу турында сөйли. Ул хәзерләүләр Наркоматының хуҗалык-финанс эшендәге күп кенә кимчелекләрнең әлегә кадәр бетерелмәгәнлеген күрсәтеп үтә.

Күп кенә хуҗалыкчылар ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын үтәмиләр әле. Съезд исә хуҗалык исәбен тагын да нығытуны, хуҗасызлыкка каршы көрәшне көчәйтүне һәм предприятиеләрнең рентабельлеген күтәрүне таләп иткән иде. Халык акчаларын дөрес һәм экономия белән тоту өчен дәүләт һәм халык алдында үзләренең җаваплылыкларын әле барлык хуҗалыкчылар да аңлап бетермәгәннәр.

1939 нчы елны авылда налог салу реформасы үткәрелде. Аны колхозчыларның бөтен күп миллионлы массасы яхшы дип каршы алды. 1939 нчы елны авыл хуҗалыгы налогы буенча 1,5 миллиард сум акча керде.

Ләкин авылда налог эшенең әле һаман да партия һәм хөкүмәт куйган таләпләрдән артта калуын икрар итәргә кирәк. Мәсәлән, ялгыз хуҗалыкчылардан налог түләүләрен җыю әле һаман да начар оештырылган. Политик яктан зур әһәмияте булган бу эштә финанс органнары җитәрлек ныклык күрсәтмиләр.

Финанс органнары 1939 нчы елны шәһәрләрдә доход налогын, культура җыемы һәм җирле налогларны җыюны яхшы гына үткәрделәр. Халыктан налог түләүләре керү планы тулаем алганда 1939 нчы елны 108,2 процентка үтәлде.

1940 нчы елга халыктан налоглар һәм җыемнар керү планы 9,7 миллиард сум итеп билгеләнде.

Депутат иптәшләр, СССР Совнаркомы сезнең раславыгызга бер үк вакытта халыктан доход налогы турындагы яңа закон проектын һәм торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турындагы яңа закон проектын кертә.

Гамәлдәге закон буенча эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакына доход налогы прогрессив шкала буенча—хезмәт хакы аена 140 сум булганда 0,6 проценттан, хезмәт хакы 600 сум һәм аннан да артыграк булганда, 3,3 процентка кадәр салына. Яңа закон буенча 600 сумнан артыграк хезмәт хакы алучы кешеләргә налог ставкаларына бер кадәр диференциация кертү күздә тотыла. Шулай ук литераторларның һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларына налог салуны тәртипкә кертү дә билгеләнә. Елына 20 мең сумга кадәр доходлары булган кешеләргә доход налогы эшчеләр һәм хезмәткәрләр белән бер тигез нигезләрдә, ә доходлары 20 мең сумнан артык булганнарга хәзерге ставкалардан кимрәк итеп планлаштырыла торган ставкаларның икенче бер прогрессив шкаласы буенча салыначак.

Кооперативлашмаган кустарьларның һәм һөнәрчеләрнең доходларына налог салу тәртибе дә үзгәртелергә уйланыла. Хәзерге закон буенча, кооперативлашмаган кустарьларның һәм һөнәрчеләрнең күпчелегенә налог ныклы доход нормаларыннан исәпләп салына. Киләчәктә бу налогны чын доходка карап салу мөвафик булачак. Бу хәл кооперативлашмаган һәм доходлары бер тигез булмаган кустарьларга налог салудагы тигезләүчелек элементларын бетерергә мөмкинлек бирәчәк.

Торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турындагы законга да шуның кебек үзгәрешләр кертелә.

1939 нчы ел безнең илебездә халыкның саклык акчаларының тагын да үсүе елы булды. Бу—большевиклар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең Советлар Союзындагы хезмәт ияләренең материаль һәм культура дәрәҗәләрен һәр яклап күтәрүгә юнәлдерелгән дөрес политикасының нәтиҗәсе.

Халык үзенең үсеп бара торган саклык акчаларының бер өлешен дәүләт заемнарына бирә, саклык кассаларына кертә.

1939 нчы елны халыкка дәүләт заемнары буенча (тиражга чыккан облигацияләр сумасын да кертеп) процентлар һәм отышлар төсендә 547 миллион сум түләнде; вкладлар буенча 200 миллион сум чамасы процент түләнде. Бу саннар хезмәт ияләре өчен үзләренең артык акчаларын дәүләт заемнарына бирү һәм үзләренең акчаларын саклык кассаларында саклау никадәр файдалы икәнлекне тагын бер кат ачык итеп күрсәтә.

Өченче бишьеллык заемының (икенче ел чыгарылышы) 1939 нчы елны таралуының йомгаклары безнең заемнарыбызның уңышын ачык күрсәтә. Бу заемга язылу хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән сумадан 1 миллиард 637 миллион сумга артып китте һәм 1938 нче елгы заемга язылу сумасыннан 29 процент артты. Монда шәһәрдәге һәм авылдагы хезмәт ияләре массасының материаль тормыш ягы үскәнлеге, аларның Ленин—Сталин партиясе эшенә һәм Совет хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгән булулары күренде.

Дәүләтнең 1940 нчы елгы бюджеты доходларында халык арасында урнаштыру буенча дәүләт заемнарыннан 7 миллиард 865 миллион сум керү күздә тотылган. Бу сума 1939 нчы елда заемнар буенча җыелган сумадан 35,8 процентка артып китә.

1939 нчы елның 1 нче январена саклык кассаларында халык вкладларының калдыгы 6 миллиард сумнан артык булды. 1940 нчы елның 1 нче январена саклык кассаларында халык вкладларының гомуми сумасы 7 миллиард сумнан артыкка җитте һәм шулай итеп бер ел эчендә 1 миллиард сумга артты.

1939 нчы елны 11.000 яңа саклык кассалары ачылды, шулардан 9.000 е авыл җирләрендә. Илебездә хәзер барлыгы 37.120 саклык кассасы бар.

1940 нчы елны тагын 4.000 яңа саклык кассалары ачарга уйланыла.

1940 нчы елны саклык кассалары 1,8 миллиард сум яңа вкладлар тартырга тиешләр.

Бюджет керемнәре чыганакларыннан берсе—дәүләт страхованиесе рессурсларыннан гыйбарәт. Хуҗалык исәбендәге оешма буларак СССР Госстрахы бюджет доходларына үзенең табышларының бер өлешен чигереп бирә. 1940 нчы елгы бюджетта бу чигерүләр, шулай ук Госстрахның дәүләт заемнары облигацияләре сатып алудан килә торган доходлары 1 миллиард 136 миллион сум булырга тиеш. Шуның өстенә край, өлкә һәм АССР бюджетларында мәҗбүри окладной страхование буенча керемнәрдән дә чигерүләр ясала. Алар 1940 нчы елга 195 миллион сумлык итеп билгеләнделәр.

Тулы булмаган саннарга караганда, 1939 нчы елны дәүләт һәм җәмагат оешмаларына, колхозларга һәм колхозчыларга, эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә 1,3 миллиард сум страхование акчасы түләнгән.

Мәҗбүри страхование белән бер рәттән ирекле страхование дә тизлек белән үсә. Мәсәлән, 1940 нчы ел башында тормышны коллектив страхованиеләүгә 12 миллионнан артык эшче, хезмәткәр һәм колхозчы тартылган; боз сугу һәм башка төрле стихия һәлакәтләре булу куркынычыннан колхозларның 35 миллион гектар чамасы җирләре ирекле тәртиптә страхованиеләнгән; колхозларның һәм колхозчыларның 22 миллион баш терлекләре окладтан тыш страхованиеләнгән.

1939 нчы елны страхование түләүләре планы 102,6 процент итеп үтәлде. 1940 нчы елга дәүләт страхованиесен тагын да үстерү билгеләнә. Страхование буенча керемнәрнең бөтен сумасы 1939 нчы елгы 2,4 миллиард сумлыктан 1940 нчы елны 2,9 миллиард сумга кадәр, ягни 20,4 процентка артырга тиеш. Иң зур үсеш—30,9 процент—ирекле страхование буенча билгеләнә.

Сезнең раславыгызга мәҗбүри окладной страхование турындагы яңа закон проекты кертелә. Дәүләт страхованиесе колхоз производствосының ныгуына һәм җәмагат милкен саклауга яхшырак булышлык итсен өчен хөкүмәт күп кенә чаралар үткәрергә кирәк дип саный. Мәсәлән, авыл хуҗалыгы культуралары буенча страхование тәэминаты нормаларын арттырырга; мөгезле эре терлекләрне, шулай ук дуңгызларны, сарыкларны һәм кәҗәләрне страхованиеләү буенча ставкаларны киметергә; яхшы нәселле атларны һәм мөгезле эре терлекләрне генә түгел, бәлки яхшы нәселле вак терлекләрне дә тулы страхование бәясе күләмендә страхованиеләүне кертергә. Терлекләр үлә калганда страхование түләве күләмен арттырырга уйланыла. Колхозның бер баш мөгезле эре терлеге яки аты өчен 150 сум урнына уртача 300 сум, ә колхозчының бер баш терлегенә 135 сум урнына 250 сум түләнәчәк. Шулай ук чәчүлекләр, бигрәк тә техник культуралар һәлак булган хәлләрдә дә түләү шактый арта.

СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетының доход өлешен үтәү өчен бөтен мөмкинлекләр барлыкны әйтеп, иптәш Зверев СССР Наркомфиныннан алып район финанс бүлегенә кадәр бөтен финанс системасының бюджетның доход өлешен үтәү һәм арттырып үтәү эшендә зур роле барлыкны күрсәтеп үтә.

Аннары иптәш Зверев дәүләт бюджетының расход өлешенә тулы рәвештә туктала.

ССР Союзының 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты буенча расходларның гомуми күләме 1939 нчы елны (беренче йомгаклар буенча) чынлыкта булган 153,1 миллиард сум урнына 179,7 миллиард сумлык итеп билгеләнә. Димәк, 1939 нчы елга чагыштырганда расходлар 26,6 миллиард сумга, ягни 17,3 процентка арталар.

1940 нчы елны бюджет сумаларының нәрсәләргә тотылачагы түбәндәге саннардан күренә (миллион сумнар белән):

Сумаларның билгеләнүе	Сумасы
Барлык расходлар	179.710,9
Шул исәптән:	
Халык хуҗалыгына	57.117,5
Культура чараларына	42.875,4
Оборона Наркоматына һәм Хәрби Диңгез Флоты Наркоматына	57.066,2
Наркомвнуделга	7.045,4
Идарәгә һәм суд учреждениеләренә	7.160,2
Заемнар буенча отышлар һәм процентлар түләүгә	2.480,0
СССР Совнаркомының һәм союзный республикалар Совнаркомнарының саклык фондларына	5.011,0
Башка расходлар	955,2

Бюджет расходларының гомуми сумасында капитал салуга финанс бирү зур әһәмият ала.

Партиянең XVIII нче съездында иптәш Сталин куйган төп экономик бурыч—алдынгы капиталистик илләрне экономик яктан да куып җитү һәм узып китү бурычы промышленностьның, авыл хуҗалыгының, транспортның һәм халык хуҗалыгының башка тармакларының төп фондларын тагын да үстерүне таләп итә. Партиянең, хөкүмәтнең һәм иптәш Сталинның үзенең кешеләр турында көндәлек кайгыртучанлыклары культура һәм көнкүреш әһәмияте булган төп фондларны киңәйтү кирәклекне дә күрсәтә.

Болар барсы да СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетында тиешенчә чагылдырылган.

1940 нчы елга капиталь эшләр күләме 36,1 миллиард сумлык итеп билгеләнде, бу—үткән елны үтәлгән капитал эшләр күләменә карата 115 процент дигән сүз.

1940 нчы елгы бюджеттан капиталь төзелешкә финанс бирүгә 24,4 миллиард сум, ягни бу эш өчен билгеләнгән барлык расходларның 67,5 процентын тотарга билгеләнә; хуҗалык органнарының үз сумалары исәбенә 11,7 миллиард сум, ягни 32,5 процент тотылачак. Аерым тармаклар буенча капиталь төзелешкә финанс бирү түбәндәгечә бүленә (миллиард сумнар белән):

Хуҗалык тармаклары	Капиталь эшләр күләме	Финанс бирү чыганаклары: СССР ның дәүләт бюджеты	Финанс бирү чыганаклары: Хуҗалык органнарының үз сумалары	Чагыштырма үлчәү (%%): Бюджет сумалары	Чагыштырма үлчәү (%%): Хуҗалык органнары сумалары
СССР халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча	36,13	24,39	11,74	67,5	32,5
Шул исәптән:					
Промышленность	19,19	13,35	5,84	69,6	30,[illegible]
Авыл хуҗалыгы	1,23	0,94	0,29	76,4	23,6
Транспорт һәм элемтә	5,44	1,74	3,70	32,0	68,0
Дәүләт сәүдәсе һәм хәзерләү оешмалары	0,37	0,14	0,23	37,8	62,2
Торак, коммуналь хуҗалык һәм социал-культура төзелеше	1,92	1,24	0,68	64,6	35,4

Әйтергә кирәк, промышленность наркоматлары системасында да капиталь төзелешкә салына торган сумаларның күп өлешен үз сумалары белән капларга тиеш булган Наркоматлар бар. Мәсәлән, промышленность буенча уртача күрсәткеч 30,4 процент булганда Наркомпищепром буенча аның үз сумалары 87,8 процент, Наркоммясомолпром буенча 82,8 процент, Наркомсредмаш буенча 63,6 процент, гомуми машина төзелеше Наркоматы буенча 55,4 процент булырга тиеш.

Капиталь төзелеш буенча бөтен программаның үтәлүен тәэмин итү—Сталинчыл өченче бишьеллык бурычларын тормышка ашыруга зур яңа байлык кертү дигән сүз. 1940 нчы елгы капитал салынышларның күләме аларның һәр бер проценты 360 миллион сумнан артык булырлык итеп билгеләнгән.

Капиталь төзелешкә финанс бирүче банкларның отчетларына караганда, 1939 нчы елны хуҗалык органнарының үз сумаларыннан 6,2 миллиард сум җыелганлыгы күренә. Бу сума үзе шактый зур, ләкин аны әле җитәрлек дип санарга ярамый, чөнки ул план буенча тупларга билгеләнгән суманың бары 92 проценты гына. Кайсы наркоматлар аеруча артта баралар? Аларны санап

(Дәвамы 3 нче биттә).

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

ИПТӘШ А. Г. ЗВЕРЕВ ДОКЛАДЫ

(Ахры. Башы 2 нче биттә).

чыгарга мөмкин. Аерым—Күмер Промышленносте Наркоматы, ул үз сумаларыннан планга карата 64,7 процент биргән, Төсле Металлургия Наркоматы—85,2 процент биргән, Уртача Машина Төзелеше Наркоматы—85,8 процент биргән, Елга Флоты Наркоматы—88,8 процент биргән.

Төзелешнең үзендә эчке ресурсларны туплау да шулай ук капитал төзелешкә финанс бирү чыганакларының берсе. 1940 нчы елны бу чыганак 1,3 миллиард сум чамасы бирергә тиеш. Безнең төзелешләрдә артык запас материаллар, җиһазлар, механизмнар күп санда саклана. Бу байлыклар еш кына бер төзелештә кирәксезгә яталар, ә шул ук вакытта башкалар аларга мохтаҗ. Аерым төзелешләрдәге җитәкчеләрнең мондый практикасын дәүләт интересларына каршы килә торган хуҗасызлык дип әйтмичә башкача әйтеп булмый.

Бездә әле һаман да төзелеш бәясе чиктән тыш югары. 1939 нчы елгы саннардан күренүенчә, аның бәясен киметү турында хөкүмәт заданиесе үтәлмәгән генә түгел, хәтта төзелешнең чын бәясе сметада күрсәтелгәннән күп кенә артып та киткән.

1940 нчы елга билгеләнә торган капиталь эшләрнең 36,1 миллиард сумлык күләме барлык капитал салынышларны да эченә алып бетерми әле. Бу сумадан тыш тагын 4,8 миллиард сумлык лимиттан тыш расходлар күздә тотыла. Шулардан 1,5 миллиард сумы Союз күләмендә әһәмияте булган наркоматлар һәм оешмалар буенча, 3,3 миллиард сумы республика күләмендә һәм җирле әһәмияте булган наркоматлар һәм оешмалар буенча. Шуның өстенә 1940 нчы елгы планда зур гына капиталь ремонт программасы билгеләнә. Ул 6,6 миллиард сумлык булачак. Капиталь ремонт расходларының 79 проценты хуҗалык оешмаларының амортизация чигерүләре исәбенә, калган өлеше бюджет исәбенә капланачак.

Тагын бер тармакка—индивидуаль торак төзелешенә кредит бирүгә тукталып үтәм.

1939 нчы елны бу эшкә 243 миллион сум кредит билгеләнде, 154,4 миллион сумлык ссуда рәсмиләштерелде, ә банктан бары 92,3 миллион сум гына алынды. Индивидуаль торак төзелешенә кредит җибәрү планының үтәлеп җитмәве—наркоматларның борыла алмаучанлыкларының турыдан-туры нәтиҗәсе. Наркоматлар лимитларны соңга калып бүлделәр, участыкларны хәзерләүне, индивидуаль торак төзелешенә җибәрелгән акчалардан дөрес файдалануны күзәтмәделәр һ. б.

Аннары иптәш Зверев союзный, республика һәм җирле хуҗалык оешмаларының үз оборот средстволарына сораулары 1941 нче елның 1 нче январена 71,1 миллиард сум итеп билгеләнгәнлекне күрсәтеп үтә. 1940 нчы елны алар 10,3 миллиард сумга үсәргә тиешләр. Бу үсешнең яртыдан артыграгы—5,3 миллиард сумы—бюджет исәбеннән капланырга тиеш.

Кызганычка каршы, күп кенә хуҗалык оешмалары оборот средстволары нормативларының чын кирәклеккә туры килүе турында аз кайгырталар.

Кайбер хуҗалык оешмаларын чиктән тыш күп материаль кыйммәт запаслары тупларга нәрсә мәҗбүр итә? Технология процессының нинди булса да махсус шартларымы? Юк. Производство өчен материалларның фактта кирәк күләмеме? Ул да түгел. Болар барсы да—төрле вәкилләрнең һәм уполномоченныйларның контрольсез эшләүләренең нәтиҗәсе генә. Бу вәкилләр һәм уполномоченныйлар бер предприятиеләрдә чималның һәм материалларның артык булуы еш кына икенче предприятиеләрдә производство программалары өзелүнең сәбәбе булуын искә алмыйлар.

МТС ларны һәм совхозларны финанслаштыру мәсьәләсенә күчеп, докладчы, 1940 нчы елны авыл хуҗалыгын тагын да үстерү күздә тотылганлыкны әйтеп үтә. Колхозларда бөртекле культуралар буенча уртача иген уңышы алу бу елга гектарыннан 11,2 центнер итеп кабул ителде. 405 яңа машина-трактор станциясе оештыру билгеләнә, шул исәптән 275 МТС УССР ның һәм БССР ның көнбатыш өлкәләрендә оештырылачак. Шулай итеп МТС ларның гомуми саны 1939 нчы елның ахрында булган 6.500 урынына 6.900 гә җитәчәк. МТС лар бер ел эчендә 30 меңләп яңа куәтле тракторлар алачаклар.

Союз буйсынуындагы авыл хуҗалыгы предприятиеләренә дәүләт бюджетыннан акча тотуның гомуми күләме быелга 11,3 миллиард сум итеп билгеләнде. Бу акчаларның төп өлеше—8 миллиард сумы, яки 70,9 проценты машина - трактор станцияләрен финанслауга юнәлдереләчәк.

Докладчы МТС ларны бюджеттан финанслауга күчерү аларның эшләрен яхшыртты, ди. Ләкин бу, машина-трактор станцияләре эшендәге зур кимчелекләрне каплап калдырмаска тиеш. МТС ларның эшендә финанс дисциплинасын бозу, тракторларга ремонт ясауда артык расход тоту фактлары еш кына була. МТС лар хөкүмәтнең акчаны саклык белән тоту турындагы күрсәтмәсен йомшак үтиләр. Наркомзем МТС ларда дәүләт акчасын тотуга әле нәтиҗәле контрольне юлга салмаган.

Хөкүмәт совхозларга финанс ягыннан зур ярдәм күрсәтә. 1940 нчы елга Наркомсовхозның бөтен системасы буенча расходларның гомуми сумасы 5 миллиард сум итеп билгеләнде, шул исәптән 2,8 миллиард сумы бюджет буенча.

Күп кенә совхозлар бөртекле ашлык продукциясе җыю һәм терлек үстерү буенча үз алларына куелган бурычларны уңышлы үтиләр. Ләкин әле канәгатьләнмәслек эшләүләрен дәвам иттерүче совхозлар да күп. Шуның нәтиҗәсендә совхозлар Наркоматы 1939 нчы елны бөртекле культуралар, ит һәм сөт буенча дәүләткә продукция тапшыру планын үтәп җиткермәде.

Совхозлар Наркоматы 1940 нчы елны кайбер хуҗалыкларда булган зур кимчелекләрне кискенлек белән бетерергә һәм дәүләт акчаларын тотуда тиешле тәртип урнаштырырга тиеш.

Партиянең XVIII нче съездында ясаган докладында иптәш Сталин эчке политика өлкәсендәге әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе итеп эшчеләрнең, крестьяннарның һәм интеллигенциянең культура хәлен тагын да яхшыртуны дәвам иттерүнең кирәклеген күрсәтте. Иптәш Сталинның шушы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән СССР хөкүмәте 1940 нчы елны культура чараларына акча җибәрүне тагын да үстерүне билгеләде. Бу теләк белән 1940 нчы елның дәүләт бюджетыннан расход тотуны 42,9 миллиард сум итеп раслау күздә тотыла. Бу—1939 нчы елгы расходлардан 4,5 миллиард сумга артыграк.

Үткән еллардагы кебек үк, культура чаралары расходларында төп урынны, табигый ки, мәгариф һәм сәламәтлек саклау расходлары алып торалар.

Мәгариф эшенә 23,2 миллиард сум, ягни 1940 нчы елны культура чараларына җибәрелә торган барлык расходларның 54,1 проценты кадәр акча җибәрелә. Бу акчаларның яртыдан артыграгы гомуми белем бирү һәм балаларны тәрбияләү кирәкләренә юнәлдерелә. ВКП(б) ның XVIII нче съезды өченче бишьеллыкта шәһәрдә гомуми 10 еллык урта белем бирүне, ә авылда һәм барлык милли республикаларда гомуми 7 еллык белем бирүне төгәлләүне һәм балаларны 10 еллык укуга тартуны киңәйтүне тормышка ашырырга карар бирде. Шуңа туры китереп, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләргә акча җибәрүне 1939 нчы елгы 7,7 миллиард сумнан 1940 нчы елны 8,7 миллиард сумга кадәр арттыру күздә тотыла. Болардан тыш шәһәрләрдә мәктәпләр төзүгә 192 миллион сум, авыл җирләрендә мәктәпләр төзүгә 301 миллион сум, мәктәп интернатларына—179 миллион сум җибәрелә. Болар барсы да безгә 1940—41 нче уку елында мәктәпләрдә 36.765 мең баланы укытырга мөмкинлек бирәчәк. Бу сан—1939—40 нчы елдагыга караганда 2.505 меңгә артыграк.

Кадрлар хәзерләүгә СССР ның дәүләт бюджетыннан 7,6 миллиард сум тоту күздә тотыла. Шулардан 2,8 миллиард сумы югары уку йортларына, 2 миллиард сумы—техникумнарга, 935 миллион сумы—фабрика, завод өйрәнчекләре мәктәпләренә һәм яңа кадрлар хәзерли торган башка мәктәпләргә, 1,1 миллиард сумы—кадрларны курсларда хәзерләүгә һәм яңадан хәзерләүгә, 230 миллион сумы—читтән торып укытуга юнәлдерелергә тиеш.

1940 нчы ел бюджеты гражданнарның сәламәтлеге турында Совет хөкүмәтенең Сталинча кайгыртучанлык күрсәтүен чагылдыра. Сәламәтлек саклау һәм физкультура расходларын 9,8 миллиард сум итеп, ягни 1939 нчы елгы шушындый ук расходлардан 1,2 миллиард сумга артыграк итеп кабул итү күздә тотыла.

Күп балалы аналарга дәүләт пособиесе бирү 1940 нчы елгы расходларда шактый зур статьяне алып тора. Аларга 1939 нчы елгы 1 миллиард 104 миллион сум урнына 1 миллиард 162 миллион сум бирү күздә тотыла.

Дәүләт социаль страхованиесе бюджеты буенча расходлар 1939 нчы елны тотылган 7,2 миллиард сум урнына 7,8 миллиард сум итеп билгеләнде. Шушы сумадан пенсияләр һәм пособиеләр буенча 5.584 миллион сум, балаларга хезмәт күрсәтүгә—700 миллион сум һәм ял йортларына, санаторийларга—1.044 миллион сум булачак.

Аннары докладчы хәзерге вакытта партия һәм хөкүмәт тарафыннан дәүләт аппаратын яхшырту һәм арзанайту буенча үткәрелә торган зур эшкә тукталып үтә. Бу дәүләт акчаларына шактый экономия ясауга китерергә тиеш.

Соңгы елларда безнең идарә аппараты нык үсте. Шуның белән бергә, хуҗалыкның үсүе уңае белән аппаратның законлы төстә үсүе белән бер рәттән, кайбер тармакларда артык буыннар да килеп чыкты, штатлар чиксез үстерелде, күп кенә артык расходларга юл куела.

Идарә аппараты структурасын һәм штатларын тәртипкә салу буенча хөкүмәт чаралары дәүләт акчаларына шактый экономия ясауга китерергә тиешләр. 1940 нчы ел дәвамында 1,7 миллиард сумнан артыграк экономия ясау күздә тотыла.

СССР Наркомфины органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган финанс контроле мәсьәләләренә тукталганнан соң, докладчы республика бюджетларына һәм җирле бюджетларга күчә. Ул, 1940 нчы ел—союзный республикаларның хуҗалык һәм культура ягыннан тагын да күтәрелүләре елы булып тора, ди.

1940 нчы елны союзный республикаларда капиталь төзелеш программасы 1939 нчы елны үтәлгән эшләр күләменнән шактый артык булачак. Халык хуҗалыгы һәм культура буенча республика һәм җирле буйсынудагы капиталь төзелешнең күләме 1940 нчы елга 3,4 миллиард сумлык итеп билгеләнә. Ягулык һәм төзү материаллары промышленносте буенча капиталь төзелеш лимитлары бигрәк тә арта.

Республика бюджетларының һәм җирле бюджетларның 1940 нчы елга гомуми күләме 42,6 миллиард сум итеп—1939 нчы елгы асылдагы расходларның беренче йомгакларыннан 3,1 миллиард сумга артыграк итеп билгеләнә. Аерым республикалар буенча бу бюджетлар түбәндәге сумаларда булачак: РСФСР—25.121,4 миллион сум, Украина ССР—8.017,5 миллион сум, Белоруссия ССР—2.114,6 миллион сум, Азербайҗан ССР—1.036,7 миллион сум, Грузия ССР—1.222,7 миллион сум, Әрмәнстан ССР—463,0 миллион сум, Төрекмәнстан ССР—520,6 миллион сум, Үзбәкстан ССР—1.476,3 миллион сум, Таҗикстан ССР—521,3 миллион сум, Казагстан ССР—1.638,8 миллион сум һәм Кыргызстан ССР—434,7 миллион сум.

Республика бюджетларын һәм җирле бюджетларны үтәү беренче чиратта республика һәм җирле финанс органнарының эш сыйфатына, совет һәм хуҗалык оешмалары тарафыннан аларга актив ярдәм күрсәтүгә бәйләнгән. Союзный республикаларның җитәкче органнары алдында, хезмәт ияләре депутатлары советлары алдында һәм хуҗалык органнарының җитәкчеләре алдында зур һәм дәүләт өчен әһәмиятле бурыч—җирле ягулык һәм чимал ресурсларыннан киң файдалану, хуҗалыктагы эчке резервларны тулысынча туплау, производство темпларын кызулату һәм шул юл белән сума туплау чыганакларын киңәйтү бурычы тора. Советлар урыннарда хезмәт ияләренең һаман үсеп бара торган таләпләрен иң күп күләмдә канәгатьләндерү өчен ресурслар эзләп табарга, шуның белән кара-каршы йөк ташуны киметүгә ярдәм итәргә, урыннарда уңышлы төстә җитештерелергә мөмкин булган товарларны башка өлкәләрдән һәм районнардан кертүне туктатырга тиешләр.

Республика һәм җирле бюджетларның гомуми расходлары күләме быел 8 процентка арта. Союзный республикаларның бюджетлары буенча культура чараларына булган расходлар 1940 нчы елны 28,9 миллиард сумга җитәчәк; халык хуҗалыгына 8,2 миллиард сум, идарә итүгә һәм суд учреждениеләрен тотуга—4,9 миллиард сум акча җибәрелә.

Культура кирәкләренә җибәрелә торган акчаларның өчтән бер өлешеннән артыграгы—10,9 миллиард сумы—гомуми белем һәм балаларны тәрбияләү расходларына җибәрелә. Сәламәтлек саклауга тотыла торган расходлардан аналарны һәм балаларны саклау учреждениеләренә җибәреләчәк расходлар аеруча зур—бу 18 процентка артачак.

УССР ның һәм БССР ның көнбатыш өлкәләрендә хуҗалыкны һәм культураны финанслау мәсьәләләренә күчеп, иптәш Зверев, үткән 6 ай эчендә Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге азат ителгән хезмәт ияләренең тормышында зур үзгәрешләр булганлыкны күрсәтеп үтә. Көнбатыш Украина эшчеләренең зур күпчелеге эшсез иде. Илдә крестьян халкының күпчелек булуына карамастан, 1938—39 нчы елда авыл хуҗалыгына акча җибәрү элекке Польша бюджетының бары 3,8 проценты кадәр генә иде, бу акчалар да алпавытлар һәм осадниклар интересларына тотыла иде. Паннар Польшасы украинлыларның һәм белорусларның культура үсешенә төрле тоткарлык ясый иде. Мәктәп көчләп поляклаштыру коралына әверелдерелгән иде. Украин һәм белорус телләрендәге матбугатны, сәнгатне һәм әдәбиятны поляк паннары рәхимсез буалар иде.

Көнбатыш Украинаның һәм Көнбатыш Белоруссиянең изелгән халыклар массасы паннар изүен героик Кызыл Армиянең ярдәме белән үз өстеннән мәңгегә алып ташлады. 13 миллион кеше азатлык алды, хезмәткә, ял итүгә, белем алуга хокук алды, совет гражданнары кебек үк, Сталин Конституциясе кояшы астында бәхетле тормышка хокук алды.

СССР Верховный Советы Сессиясе раславына кертелгән СССР дәүләт бюджеты Советлар Союзының яңа гражданнарының бу хокукларын канәгатьләндерүгә күп кенә акча тотуны күздә тота. Иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә: „Милли тигез хокуклылык политик яктан яулап алына торган гаять әһәмиятле нәрсә, ләкин әгәр бу гаять әһәмиятле хокуктан файдалану өчен җитәрлек ресурслар һәм мөмкинлекләр булмаса аларның буш тавыш булып калу куркынычы бар". Советлар Союзының мондый мөмкинлекләре бар һәм ул Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләренә социалистик стройның өстенлекләрен тизрәк сизәргә ярдәм итү өчен бернинди чыгымнар алдында да туктап калмаячак.

УССР ның һәм БССР ның көнбатыш өлкәләрендә хуҗалыкны һәм культураны үстерүгә союзный әһәмияте булган чараларга булган расходлардан тыш хөкүмәт 1940 нчы елны 2 миллиард сум чамасы акча тотуны билгеләде. 1940 нчы елгы бюджетның көнбатыш өлкәләргә кагылышы булган гомуми күләме Украина ССР буенча 1.204 миллион сум һәм Белоруссия ССР буенча 726 миллион сум итеп билгеләнде.

Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендә башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләр челтәре киңәйтелә. Бу өлкәләрдә мәктәпләрдә укучылар саны 1940 нчы елны ук инде 2 миллион чамасы кеше булачак. Балалар учреждениеләре, балалар бакчалары, балалар йортлары, клублар ачыла. 550 мең укый-яза белмәүче һәм аз укый-яза белүче өчен уку оештырыла.

Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге дәвалау учреждениеләрендә 6.286 койка артачак. Шуларның 1.600 е авыл больницаларында. Бу урыннарда беренче тапкыр буларак, 8 меңнән артык бала сыйдырырлык (шәһәрләрдә һәм авылларда) ясләләр һәм бала тудыру йортлары ачыла. Дәүләт социаль тәэминатына 60 меңнән артык кеше кабул ителәчәк.

Сталин Конституциясе байрагы астында, халыкларның бөек юлбашчысы иптәш Сталин җитәкчелегендә Белоруссиянең һәм Украинаның көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләре шатлыклы азат тормышта яши башладылар.

Соңыннан докладчы оборона расходларына туктала.

Иптәш Зверев болай ди:

— Иптәшләр! Без сезнең белән, бөтен совет халкы кебек үк, әле капиталистик чолганыш яшәгәндә социализм иленә империалистларның һөҗүм куркынычы һәр вакыт булачаклык белән хисаплашу турында иптәш Сталин күрсәтмәсен бер генә минутка да онытмаска тиешбез.

Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты җиңүчән социализмның героик тарихына соңгы вакытта күп кенә яңа, гүзәл сәхифәләр яздылар.

Ерак Көнчыгышта социалистик Ватаныбызны дошманнар һөҗүменнән саклаганда һәм Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын азат итү буенча үзләренең тарихи бурычларын үтәгәндә Кызыл Армиянең сугышчылары, командирлары һәм политработниклары батырлыкның, үз-үзеңне аямаучанлыкның һәм кыюлыкның онтылмаслык үрнәкләрен күрсәттеләр. Алар бөтен илебез горурлана торган батырлыклар эшләделәр.

Ак финнәргә каршы көрәш фронтында Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты сугышчылары гаять зур геройлык күрсәттеләр. Бу көрәш совет коралының һәм совет тынычлык политикасының тантанасы белән тәмам булды.

Безнең данлыклы Кызыл Армиябез һәм Хәрби Диңгез Флотыбыз сугышчыларының, командирларының һәм политработникларының данлыклы батырлыкларында социализм иле гражданнарының Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлекләре чагылган.

Күп кенә империалистик дәүләтләрнең берләштерелгән көчләрен гүзәл төстә җиңеп, Кызыл Армия һәм флот „Безнең халкыбызда батырлык, үз-үзеңне аямаучылык һәм геройлык чыганагы бетмәслек" (В. М. Молотов) икәнлекне бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Партиянең һәм хөкүмәтнең чакыруы белән, үзләренең Ватаннарына, большевиклар партиясенә һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгән миллионнарча совет кешеләре социалистик Ватанны һәр төрле дошманнарның һөҗүмнәреннән саклауга бер кешедәй булып нинди генә минутта да күтәрелерләр, Ватан өчен, Сталин өчен, коммунизм өчен сугышка барырлар. **(Кул чабулар).**

СССР хөкүмәте 1940 нчы елны оборонага 57 миллиард сум акча җибәрергә тәкъдим итә һәм СССР Верховный Советыннан бу суманы раслауны сорый. **(Озакка сузылган кул чабулар).**

Депутат иптәшләр! СССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан ССР Союзының сезнең карамагыгызга кертелгән 1940 нчы елгы дәүләт бюджетының Сталинчыл өченче бишьеллыкның тарихи бурычларын тормышка ашыру өчен көрәштә гаять зур әһәмияте бар.

1940 нчы елгы бюджетны үтәү ВКП(б) ның XVIII нче съезды һәм иптәш Сталин тарафыннан куелган бурычларны тормышка ашыру эшендә куәтле вклад булыр. **(Кул чабулар).**

Иптәш А. Г. Зверев доклады кыскартылган стенограмма буенча басыла.

СОЮЗ СОВЕТЫНЫҢ ҺӘМ МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

31 март, 1940 ел

31 нче мартта, кич 6 сәгатьтә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән икенче утырышы булды.

Утырышта Милләтләр Советы Председателе депутат **Н. М. Шверник** председательлек итә.

СССР Верховный Советы Сессиянең көн тәртибенең икенче мәсьәләсен—„Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турында" гы мәсьәләне карауга керешә.

Бу мәсьәлә буенча докладны СССР Халык Комиссарлары Советы исменнән депутат **А. А. Жданов** ясый. Депутатлар аны озакка сузылган кул чабулар һәм алкышлар белән каршы алалар.

Иптәш **Жданов** доклады буенча фикер алышуларда депутатлардан **П. В. Соляков** (Карелия АССР ның Кемь округы), **М. В. Горбачев** (Карелия АССР ның Сорока округы) һәм **Б. А. Двинский** (Ростов өлкәсенең Таганрог округы) иптәшләр катнашалар.

Депутат **Двинский**ның тәкъдиме буенча СССР Верховный Советы фикер алышуларны туктату турында карар кабул итә һәм СССР Халык Комиссарлары Советы керткән закон проектын раслауга күчә.

Палаталарда аерым рәвештә тавышка кую юлы белән СССР Верховный Советы „Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү турындагы закон" ны бер тавыштан раслый.

„Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы хезмәт ияләренең теләген үтәү йөзеннән һәм милләтләрнең ирекле үсеше принципын кулланып, Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы карар бирә:

1. 1940 нчы елның 12 нче мартында СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договоры нигезендә Финляндиядән СССР га күчә торган территорияне, турыдан-туры Ленинградка караган кечрәк полосадан башкасын, Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасы составына тапшырырга, шул исәптән Выборг, Антреа, Кексгольм, Сортавала, Суоярви, Куолаярви шәһәрләрен тапшырырга.

2. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзергә.

3. Шушы законның беренче пункты буенча Карелия составына кушыла торган территориядә урнашкан промышленность предприятиеләрен, бөтен Союз күләмендә әһәмияте булган аз гына сандагы предприятиеләрдән башкаларын, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы карамагына тапшырырга.

4. Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советыннан һәм Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы Верховный Советыннан РСФСР белән Карел-Фин ССР арасында төгәл чикне билгеләү проектын СССР Верховный Советы карамагына кертүләрен сорарга.

5. СССР Конституциясенең (Төп Законының) 34 һәм 35 статьяләренә туры китереп, Карел-Фин Совет Социалистик Республикасыннан СССР Верховный Советына депутатлар сайлау үткәрергә.

6. СССР Верховный Советы Президиумына бу сайлауларның көнен билгеләүне тапшырырга.

7. Шушы законга туры китереп, СССР Конституциясенең (Төп Законының) 13 нче статьясенә өстәмә кертеп, аны түбәндәгечә язарга:

„**13 статья.** Совет Социалистик Республикалар Союзы тигез хокуклы Совет Социалистик Республикаларның:

Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының,

Украина Совет Социалистик Республикасының,

Белоруссия Совет Социалистик Республикасының,

Азербайҗан Совет Социалистик Республикасының,

Грузия Совет Социалистик Республикасының,

Әрмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Төрекмәнстан Совет Социалистик Республикасының,

Үзбәкстан Совет Социалистик Республикасының,

Таҗикстан Совет Социалистик Республикасының,

Казагстан Совет Социалистик Республикасының,

Кыргызстан Совет Социалистик Республикасының,

Карел-Фин Совет Социалистик Республикасының ихтыярлы берләшүләре нигезендә төзелгән союз дәүләте".

Аннары СССР Финанс Халык Комиссары иптәш **А. Г. Зверев** Сессиянең көн тәртибенең өченче пункты буенча—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турында доклад ясады.

Шуның белән Союз Советының һәм Милләтләр Советының берләштерелгән икенче утырышы ябылды.

ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ СОВЕТ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ТЫШКЫ ПОЛИТИКАСЫН БЕРДӘМ РӘВЕШТӘ ЯХШЫ ДИП ТАБАЛАР

Илебезнең куәтен тагын да ныгытырбыз

Совет хөкүмәте башлыгы һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш Молотов докладын өйрәнүгә багышланган митинг „Спартак“ комбинатында гаять зур күтәренкелек, оешканлык белән үтте. ВКП(б) райкомы вәкиле иптәш Мексина белдерүеннән соң чыгып сөйләүче стахановчы, шәһәр советы депутаты иптәш Селихова митингта катнашучыларның бердәм фикрен белдереп болай диде:

— Иптәш Молотов СССР Верховный Советының VI нче Сессиясендә сөйләгән докладында данлыклы Кызыл Армиябез батырлыкларын конкрет фактлар белән күрсәтте. Безнең ил—ул геройлар иле. Безнең ил ул тынычлык маягы. Кызыл сугышчыларыбызның батырлыклары белән чиксез шатланган хәлдә, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә актив ярдәм күрсәтергә, Ватаныбыз тынычлыгын күкрәк белән сакларга һәр вакыт хәзер торабыз. Без дошманны теләсә генә нинди шартларда да рәхимсез рәвештә үз территориясендә юк итәрбез.

Аннан соң чыгып сөйләүче Евстафьева, Сидоров һәм башка иптәшләр дә хөкүмәтебезнең тынычлык политикасын бердәм рәвештә якладылар һәм илебезнең куәтен тагын да ныгыту өчен намус белән эшләргә сүз бирделәр.

Хөкүмәтнең тышкы политикасын котлыйбыз

31 нче мартта мехкомбинатның барлык предприятиеләрендә күп кеше катнашы белән митинглар булды. Аларда 3 меңгә якын кеше катнашты. Митингларда катнашучылар хөкүмәтнең тышкы политикасы турында Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотов доклады турындагы белдерүне зур күтәренкелек белән тыңладылар.

Митингларның бер тавыштан кабул ителгән резолюцияләрендә болай диелә:

— Без, Казан шәһәренең мех фабрикаларындагы эшчеләр һәм хезмәткәрләр, барыбыз бер кешедәй булып, Совет хөкүмәтенең тышкы политикасын кайнар рәвештә котлыйбыз. Безнең Кызыл Армиябез җиңелмәслек булды һәм шулай булып кала. Фин ак гвардеецларына каршы көрәштә батыр сугышчылар, командирлар һәм политработниклар, совет халкы теләген үтәп, Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының җимерелмәслек куәтен тагын бер тапкыр күрсәттеләр.

Хөкүмәтебезнең политикасын тулысы белән яхшы дип табып, мехчылар коллективы партиябезне, хөкүмәтебезне һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталинны, хезмәтнең җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү өчен, сөекле Ватаныбызның хәрби көчен тагын да ныгыту өчен мехчылар үзләренең барлык көчләрен һәм энергияләрен бирерләр дип ышандыра.

Һәр вакыт мобилизацион хәзерлектә булырга

Авиация институтында 31 нче мартта СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә иптәш Молотов докладына багышланган митинг зур күтәренкелек белән үтте.

Митингта чыгып сөйләүче студент иптәш Есипов болай диде:

— Фин ак гвардеецларына каршы сугышларда Кызыл Армия үзенең җиңелмәслеген һәм Совет җиренең изге чикләренә бер генә интервентны да җибәрмәячәген бөтен дөньяга күрсәтте.

Фәнни работник иптәш Чусляев болай диде:

— Англия—Франция империалистларының советка каршы планнары иптәш Молотов докладында бик яхшы итеп фаш ителделәр. Дошманнарның провокацияләренә җавап итеп без, Ватаныбызның оборонага сәләтлелеген тагын да ныгытырбыз, оборона эшен тагын да киң җәелдерербез.

Гражданнар сугышында катнашучы иптәш Толстогузов болай диде:

— Финляндия фронтында Кызыл Армиянең җиңүе Ленинградка һәм безнең төньяк-көнбатыш чикләребезгә куркынычсызлыкны тәэмин итте. Ләкин без тынычланып калмаска тиешбез. Һәр вакыт уяу булырга һәм дәүләтебезнең куәтен стахановча эш белән ныгытырга кирәк. Һәр вакыт мобилизацион хәзерлектә булырга кирәк.

Җыелыш, бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә Совет хөкүмәтенең тышкы политикасын тулысы белән яхшы дип тапты. Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының оборона куәтен тагын да ныгыту өчен барлык хезмәт ияләрен көрәшкә чакырды.

СССР НЫҢ ОБОРОНА КУӘТЕН КӨН САЕН КӨЧӘЙТЕРГӘ

31 нче мартта кич белән Каргалы авылында (Кызыл Армия районы) СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе ачылуга һәм иптәш Молотов докладына багышлап район үзәгендәге эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең һәм „Беренче Май“ колхозы членнарының митингысы булды. Митингта 200 дән артык кеше катнашты.

Митингта иптәш Молотов доклады турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Тараканов кыскача речь сөйләде. Митингта катнашучылар бер тавыштан резолюция кабул иттеләр. Резолюциядә болай диелә:

— Без, Каргалы авылының хезмәт ияләре, хөкүмәтебезнең тышкы политикасы турында СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясендә иптәш Молотов доклады турындагы белдерүне тыңлагач, бөтен совет халкы һәм бөтен дөнья хезмәт ияләре интересларын тулы итеп чагылдыручы Совет хөкүмәтенең Сталинчыл зирәк тышкы политикасын бер тавыштан һәм кайнар рәвештә яхшы дип табабыз.

Ак гвардеецларга каршы, безнең төньяк-көнбатыш чикләребезгә һәм Ленин шәһәренә куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен көрәштә данлыклы улларыбызның батырлыкларын гаять зур игтибар белән күзәтеп тордык.

Без илебезнең оборона куәтен көн саен ныгытырга һәм хәрби эшне өйрәнергә, оборона оешмаларыбызның эшен яхшыртырга, язгы чәчүне иң кыска срокларда югары сыйфатлы итеп үткәрергә чын күңелдән йөкләмә алабыз.

СССР НЫҢ ТЫШКЫ ПОЛИТИКАСЫ ТУРЫНДА ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВНЫҢ СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ VI НЧЫ СЕССИЯСЕНДӘ ЯСАГАН ДОКЛАДЫ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

ГЕРМАНИЯ

БЕРЛИН, 31 март. (ТАСС). Германиянең кичәге газеталары иптәш Молотов докладына откликлар урнаштыруны дәвам иттерделәр. Кичке „Дейче альгемейне цейтунг“ газетасы үзенең Москвадагы хәбәрчесенең мәкаләсен беренче биткә урнаштырды. Хәбәрче болай дип яза: „Үзенең докладында Молотов Совет тышкы политикасының төп пунктларын бөтен ачыклыгы белән тагын бер кат аңлатып бирде. Сессия Совет хөкүмәтенең тышкы политикасын тулысынча яхшы дип тапты. Советлар Союзының үзенең чын интересларын саклаячаклыгы турында Молотов һичбер төрле шик калдырмады. Молотовның бу белдерүен кул чабулар белән каршы алдылар һәм бу хәл тынычлыкка омтылышны күрсәтте“.

Германиянең бүгенге газеталары иптәш Молотов докладына зур игтибар бирүне дәвам иттерә. Зур провинцияләрдә чыга торган „Франкфуртер цейтунг“, „Гамбургер фремденблат“ һәм башка газеталарда иптәш Молотов докладыннан зур өзекләр урнаштырылган. Германия чит ил эшләре министрлегенең рәсми газетасы булган „Дейче дипломатиш политише корреспонденц“ газетасы иптәш Молотов докладына багышлап зур мәкалә урнаштыра. Бу мәкаләдә СССР ның тышкы политикасы аның үз куркынычсызлыгын тәэмин итүгә генә түгел, бәлки тынычлыкны саклау белән кызыксынучы барлык халыкларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә хезмәт итә дип күрсәтелә.

ТӨРКИЯ

ӘНКАРӘ, 31 март. (ТАСС). Төркия матбугаты иптәш Молотов докладын киң рәвештә иглан итә. „Җөмһүрият“ газетасы докладны түбәндәге башлар астында бирде: „Молотов гаять әһәмиятле речь сөйләде. Маннергейм линиясендә СССР ның барлык империалистларга каршы сугыш алып барганлыгы турында сөйләде. Молотов Россиянең агрессив теләкләре булмаганлыгын күрсәтеп үтте. СССР белән Төркия арасында бер нинди конфликт юк. СССР үзенең күршеләренең дошманлык хәрәкәте коралы булып әверелмәүләрен күзәтәчәк“. Докладта СССР ның көньяктагы күршеләре белән мөнәсәбәтләре турындагы бүлекне газета тулысынча һәм курсив белән урнаштырды. Шулай ук иптәш Молотов докладының күп кенә бүлекләрен урнаштырып, газета иптәш Молотовның Кызыл Армия үзенең көчен күрсәтте һәм СССР киләчәктә дә үзенең оборонасын ныгытачак дигән сүзләрен аеруча күрсәтеп үтә.

„Таң“ газетасы иптәш Молотов докладының эчтәлеген түбәндәге баш астында бирә: „Молотов СССР ның сугышка керешмәячәген белдерде. Иран һәм Төркия белән мөнәсәбәтләр турында совет баш министре аларның һөҗүм итешмәү турындагы пактларга нигезләнүен һәм СССР ның үз йөкләмәләрен үтәргә теләвен белдерде“.

„Републик“ һәм „Журналь дорион“ газеталары беренче битләрендә иптәш Молотов докладының кыскача эчтәлеген һәм аның портретын урнаштырдылар.

ВЕНГРИЯ

БУХАРЕСТ, 31 март. (ТАСС). Венгрия матбугаты кичә СССР Верховный Советы Сессиясенең ачылуы турында һәм иптәш Молотов доклады турында иглан итте. „Пестер Ллойд“, „Мадьяршаг“, „Мадьяр немзет“ һәм башка газеталар Англия—Франция блогының Германиягә каршы сугышында СССР нейтралитет политикасы тота, дип күрсәтеп үтәләр.

ГОЛЛАНДИЯ

БЕРЛИН, 31 март. (ТАСС). Германия информация бюросының Гаагадан хәбәр итүенә караганда, Голландиянең күпчелек газеталары иптәш Молотов докладын зур хәрефләр белән һәм тулысынча аңлатып басып чыгардылар. Голландия җәмагатчелеге иптәш Молотов докладына зур игтибар бирә. Газеталар иптәш Молотовның Скандинавиядәге „оборона союзы“ турындагы сүзләрен аеруча күрсәтеп үтәләр.

КӨНЬЯК СЛАВИЯ

СОФИЯ, 31 март. (ТАСС). Көньяк Славия матбугаты иптәш Молотов докладын тулысы белән урнаштыра һәм Советлар Союзының нейтралитетны сакларга теләвен аеруча күрсәтеп үтә.

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 31 март. (ТАСС). „Слово“ газетасы редакция исменнән язылган „Россиянең тынычлык сөюе“ дигән мәкаләсендә иптәш Молотов докладын аңлата. Газета болай дип яза: „СССР Верховный Советы Сессиясе утырышында Молотов доклады Советлар Россиясенең тынычлыкны сөюче тышкы политикасын иң нык төстә раслау булды. СССР сугышырга һәм башкалар өчен утлы күмер чүпләргә теләми. Бу турыда Совет хөкүмәте сугыш башланганда ук инде кискен төстә белдергән иде“. Газета, әгәр патша Россиясен башка илләр күп тапкырлар үз интересларында файдаланган булсалар, хәзер бу эш барып чыкмас, дип яза.

КЫТАЙ

ЧУНЦИН, 31 март. (ТАСС). „Чжунянжибао“ газетасы, иптәш Молотов докладын аңлатып, болай дип яза: „Молотов доклады—СССР ның тыныч тышкы политикасын бик яхшы аңлату. Советлар Союзы—Европада тынычлыкның әһәмиятле факторы. Ерак Көнчыгышта тынычлык урнаштыру эшендә СССР ның йогынтысы аеруча зур. Тынычлык өчен көрәштә Советлар Союзы тарафыннан күрелгән эшнең һәм тырышлыкның бәясен бөтен дөнья икрар итә“.

ШАНХАЙ, 31 март. (ТАСС). Шанхайда чыга торган иртәнге кытай газеталары барсы да диярлек бүген „СССР ның тынычлык политикасы Европа сугышын киңәйтүгә тоткарлык ясый“ дигән баш астында иптәш Молотов докладының беренче яртысын басып чыгардылар. Газеталар барсы да докладның дәвамы алдагы номерда басылачак турында иглан иттеләр.



Актаныш районы „Кызыл Көч“ колхозының хата-лабораториясе каршында оештырылган стахановчылар мәктәбендә укучылар занятие вактында. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ АЛДЫННАН

Рейдне большевистик оешканлык белән үткәрик

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карары нигезендә язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде башланды.

Эшче-авыл хәбәрчеләре рейде турында күп кенә урыннардан хәбәрләр килә башлады. Норлат районының „Путь Ленина“ газетасы редакциясе 14 бригада һәм „Ярыш“ газетасы редакциясе 17 бригада оештырдылар. Рейд бригадасы членнары белән инструктаж үткәрелгән. Хәзер күпчелек бригадалар колхозларда практик эш алып баралар.

Рейд бригадасының составы 3—5 кешедән тора. Бригада членнарының күпчелеге хәбәрчеләр һәм стена газетасы редакторлары. „Красная гора“ колхозын тикшерү бригадасына „Путь Ленина“ газетасы редакторы иптәш Налимов, Вахитов исемендәге колхозны тикшерү бригадасына ВКП(б) райкомы работнигы—хәбәрче иптәш Низамиев һәм „Игенче“ колхозындагы бригадага авыл хәбәрчесе иптәш Салахов җитәкчелек итә. Рейд нәтиҗәләрен яктырту буенча район һәм стена газеталарының махсус номерлары чыгарылачак.

Теләче районында партия, комсомол активыннан һәм хәбәрчеләрдән 9 бригада оештырылган. Бу бригадаларга 29 кеше тартылган. Алардан 13 кеше авыл хуҗалыгы белгечләре, Сталин исемендәге совхозда, Мулланур Вахитов исемендәге колхозда һәм „Кызыл Көч“, „Төрек баш“, „Кызыл Янбулат“, „Марс № 2“, „Чулпан №2“ колхозларында рейд бригадалары эшкә керештеләр инде. Район газетасының шушы көннәрдә чыгачак номеры рейд материалларын яктыртуга багышланачак.

Шуның белән бергә, кайбер районнарда бу эшкә формаль карау, эшче-авыл хәбәрчеләренең инициативасын, аларның активлыгын томалап калдыруга омтылу фактлары да бар. Мәсәлән, Буа районында бу эш буенча район комиссиясе оештырылган. Комиссия членнары урыннарга барып, рейд оештырырга кирәклек турында әйтеп чыгарга тиешләр. Алар үзләре рейд бригадалары составына кермиләр һәм бу эшкә турыдан-туры җитәкчелек итмиләр. Болай оештыру ансаттыр, әлбәттә. Ләкин моннан нәтиҗәле эш көтүе кыен.

Чепья районы редакциясе янында бер нинди дә рейд бригадалары оештырылмаган. Рейдне урыннарда оештыру турында ВКП(б) райкомының колхозларга чыгучы вәкилләренә әйтеп чыгарганнар. Бу вәкилләр үзләре 5 нче апрельгә кадәр урыннарда булачаклар. Бәлки кайберләре тизрәк тә борылып кайтырлар? Бу, рейд оештыру түгел, бәлки эшче-авыл хәбәрчеләре рейден янәдән вәкилләр җибәрүгә кайтарып калдыру дигән сүз.

Бу өлкәдәге төрле бозуларны, формаль карашларны кичекмәстән бетерергә кирәк. Рейдне үткәрүгә хәбәрчеләр никадәр күп һәм актив катнашсалар, аларның хәбәрчелек эшендә вакыйгаларне дөрес күрү, материал җыйнарга өйрәнү, хәбәрне оештыра һәм яза белү осталыклары шул кадәр үсәчәк. Рейднең әһәмияте аның массовый булуында һәм халык белән тыгыз аралашкан авыл хәбәрчеләренең, стена газетасы редколлегиясе членнарының, колхоз, совхоз стахановчыларының актив катнашуларында.

Рейдкә катнашучыларга бер нинди дә администрация хокуклары бирелми. Аларның бурычы—артта калучыларга ярдәм итү, иң яхшы тәҗрибәләрне башкаларга күчерү, кимчелекләрне һәм аларны китереп чыгаруда гаеплеләрне большевикларча тәнкыйть итүдән гыйбарәт. Рейднең иң әһәмиятле шартларыннан берсе—нәтиҗәлелек өчен көрәшү, һәрбер күренгән кимчелекнең шунда ук бетерелүенә ирешү һәм бу мәсьәләләрне өлкә, район газеталары һәм стена газеталары битләрендә киң күләмдә яктырту.

ВКП(б) райкомнары һәм район газетасы редакцияләре рейд бригадаларына шушы максатлардан чыгып җитәкчелек итәргә, рейдне уңышлы үткәрү өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

ТРАКТОРЛАР УЧАСТКЫЛАРГА ЧЫКТЫЛАР

МӨСЛИМ, 31 март. (Телефон буенча). Мөслим МТС ының барлык трактор отрядлары колхозларга, участкыларга киттеләр. Алар мөмкинлекләр туу белән эшкә керешергә хәзер торалар.

Алга МТС ының да 4 отряды үзләре эшләячәк участкыларга киттеләр. Шушы көннәрдә, башка отрядлар да колхозларга китәчәк. Ләкин 4 трактор моторының ремонттан чыкмау нәтиҗәсендә отрядларны колхозларга җибәрүгә тоткарлык ясый. Бөгелмә МТМ ы Алга МТС ының 24 трактор моторының 28 нче мартка 20 трактор моторына гына ремонт ясады (срок 1 нче март иде). *Шәйми.*

ӘЛМӘТ, 29 март. (Телефон буенча). Әлмәт МТС ы тракторларга һәм тагылма коралларга ремонт эшләрен тәгәлләде. Әхмәтҗанов һәм Юнусов иптәшләр ике күчмә мастерской хәзерлиләр. МТС ның 17 трактор бригадасы да кирәкле кадрлар белән тәэмин ителде. Бригадалар участкыларга беркетелде. Трактор бригадалары, язгы чәчүне кыска срокта үткәрү һәм еллык производство планын арттырып үтәү буенча конкрет йөкләмәләр алып, үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр.

Иптәш Мостафин бригадасы Камалиев бригадасын ярышка чакырды. Иптәш Мостафин үткән ел һәрбер трактор белән уртача 1.200 гектар җир эшләп, еллык планны 140 процентка үтәгән иде. Ул быел СТЗ тракторы белән 1.300 гектар, чылбырлы трактор белән 1.800 гектар җир эшләргә, ягулыкка 15 процент экономия ясарга һәм эш өстендә хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү йөкләмәсен алды.

Әхмәтев һәм Салахов, Хәйреттинев иптәшләрнең бригадалары тулы хәзерлек белән участкыларга чыгып киттеләр. График буенча барлык бригадалар да 2 нче апрельгә кадәр колхозарлда булырга тиешләр. *З. Салахеттинов.*

ЗВЕНОЛАР... КӘГАЗДӘ ГЕНӘ ӘЛЕ

Кайбыч районы, „Беренче Май“ колхозында үткән ел да хезмәт звенолап оештырылмады, быел да бу эшкә игтибар бирелми. Дөрес, колхозда звенолар оештырылган, ләкин алар әле кәгаздә генә звено саналалар. Звеноларга участкылар беркетелмәгән. Ефремовчы бер звено оештырылган иде, аның да чынлап эшкә керешкәне юк. Звенолар оештыру, аларга участкылар беркетү мәсьәләләрендә аңлашылып җитмәгән нәрсәләр күп. Ләкин район җир бүлеге дә һәм МТС та бу мәсьәләләрне чишүдә колхоз правлениесенә булышлык күрсәтмиләр.

Л. Җиһаншин.

ЕЛГАЛАРДА

Беренче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Волга суы Горький янында 6 сантиметр, Вязовые янында 28 сантиметр, Югары Ослан янында 33 сантиметр, Кама Тамагы янында 18 сантиметр артты. Ташу башланганнан бирле Югары Ослан янында арткан су 116 сантиметрга җитте.

Кама суы бер тәүлек эчендә Красный Бор янында 7 сантиметр, Алабуга янында 15 сантиметр, Соколки янында 28 сантиметр, Чистай янында 31 сантиметр артты.

Оканың югары ягында боз ага. Ока суы Калуга янында 181 сантиметр, Рязань янында 36 сантиметрга артты.

Соңгы бер тәүлек эчендә Зея суы Борындык янында 198 сантиметр, Казанка суы Арча янында 82 сантиметр артты.

СУД

СПЕКУЛЯНТ

Мөслим районы, Иске Чекмак авылы гражданы Шакир Файрушин 1939 нчы елның сентябрь аеннан башлап сыерлар алып сату белән шөгыльләнгән. Ул барлыгы 15 баш сыер алып саткан һәм шул юл белән 2.000 сумнан артык табыш җыйган.

Спекулянт Файрушин суд җаваплылыгына тартылды. Мөслим районы халык суды аны 5 елга ирекеннән мәхрүм итүгә хөкем итте.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Мәктәптән урлаучылар. Шушы көннәрдә Бөгелмәнең тулы булмаган урта мәктәбенә караклар кереп 1.500 сумлык мануфактура, патефон пластинкалары һәм башка әйберләр урлаганнар. Берничә көннән соң шунда ук Осоавиахим р[illegible]ы һәм РОКК бинасыннан 2.000 сумл[illegible] противогазлар, скәтерләр урланган. Милиция работниклары тарафыннан чаралар күрелгәч, җинаятчеләр тотылганнар. Алар Бөгелмә шәһәрендә торучы Е. Н. Антонов һәм П. Л. Курьянов дигән күптәнге җинаятчеләр булып чыкканнар. Антоновның анасы Мария Антонова, урланган әйберләрне үзенең квартирасында яшереп тоткан. Урланган әйберләрнең 3 мең сумлыгы табылган. Урлаучылар суд җаваплылыгына тартылалар.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 2 нче апрельдә премьера
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
2, 3 һәм 4 нче апрельдә
В. Шкваркин әсәре премьера
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Иртәгә, 3 нче апрельдә
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
4 нче апрельдә
ИРЕК
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8-20.	КАБАРДА АТЛЫСЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм Дипкурьер сум[illegible]ы
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК

КИРӘК:

Түләүле поликлиникада эшләү [illegible] ТӘҖРИБӘЛЕ РЕГИСТРАТОРША. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Университет урамы, 17, Иске клиника бинасы. Телефон 10—27. 557—1

Казандагы Күчерү-Бүлү нефтебазасына ЙӨК ТАШУЧЫЛАР, НЕФТЬ САЛУЧЫ ЭШЧЕЛӘР, БОНДАРЬЛАР, ЯРДӘМЧЕ БОНДАРЬЛАР, КОЧЕГАРЛАР, КОМЕРОНЩИКЛАР, ТИМЕРЧЕ, ЧҮКЕЧ СУГУЧЫ, МОТОРЧЫ, КАССИР ҺӘМ АВТОТРАНСПОРТТА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ГРУЗЧИКЛАР.

Тулай торакта урын бирелә. Хезмәт хакы эш башыннан һәм вакытлап түләнә. Казан, Яңа бистә, Зур Ямашев урамы, 2, Нефтебаза конторасы. 572—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1343 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1223.